ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап турында

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Казан (Идел буе) федераль университетының Татарстан Республикасы икътисады өчен кадрлар әзерләүгә керткән зур өлешен, Татарстан Республикасының социаль өлкәсе өчен кадрларны яңадан әзерләүдә һәм аларның квалификацияләрен күтәрүдә актив катнашуын, Казан (Идел буе) федераль университетының Медицина-санитария часте (Университет клиникасы) потенциалын кулланып, республиканың сәламәтлек саклау системасын алгарышлы үстерүгә керткән өлешен, университетның төбәк икътисадының чынбарлыктагы секторы предприятиеләре белән нәтиҗәле хезмәттәшлек системасы төзүен, Татарстан Республикасының фәнни-инновацион куәтен ныгыту өчен фәнни мәкаләләр бастыру активлыгында университетның алдынгы позицияләрен, өч мәктәп, «IT-лицей» махсуслаштырылган укыту фәнни үзәген дә кертеп, һәм аутистик спектр җитешсезлекләре булган балалар өчен балалар бакчасы базасында республиканың мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирүне үстерүгә университетның керткән өлешен билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны хупларга.

2. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында үстерү программасын гамәлгә ашыру эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе белән берлектә «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең «КФУ технопаркы» инновация-технология үзәген инновация мәйданчыкларына, сәнәгать паркларына һәм эшкуарлыкка ярдәм итүнең республика системасына кертү мөмкинлеген карауны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар белән берлектә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар студентларының, укытучыларының һәм фәнни хезмәткәрләренең инновацион тәҗрибә-юнәлеш проектларына ярдәм итү механизмнарын, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 8213 номерлы карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы кысаларында, булдыру мөмкинлеген карарга.

4.2. Татарстан Республикасында импортны алыштыру производстволарын булдыруны кызыксындыру чараларын эшләгәндә Россия фәнни мәктәпләре тикшеренүләрен һәм эшләнмәләрен анализларга һәм алардан файдалану чараларын күрергә.

5. Әлеге карарны Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 16 марты
№ 1368-VI ДС